Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Кубас авыл җирлеге башлыгы
Карары

2020 елның 30 октябре № 11

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Чистай муниципаль районы Кубас авыл җирлегенең Кубас авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чистай муниципаль районының «Кубас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 24 ноябрендә 14.00 сәгатькә клуб бинасында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кубас авыл җирлегенең Кубас авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: ТР, Чистай районы, Кубас авылы, Үзәк ур., 3 нче йорт.
2. 2020 елның 24 ноябрендә 14.00 сәгатькә клуб бинасында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кубас авыл җирлегенең Кубас авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: ТР, Чистай районы, Кубас авылы, Үзәк ур., 3 нче йорт.
3. Гражданнарның этаплап җыенын үткәрү өчен Татарстан Республикасы Кубас авыл җирлегенең Кубас авылында яшәүчеләр исемлеген 2 өлешкә бүләргә:
   1) Овражная ур., Камская ур., Озерная ур.;
   2) Үзәк ур., Мәктәп ур., Киң ур., Садовая ур., Кыр ур.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2021 елда Чистай муниципаль районы Кубас авыл җирлегенең Кубас авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризалашасызмы:

- Кубас авылы урамнарын ремонтлау (вак таш сатып алу һәм китерү, грунт салу һәм грейдирование, вак таш салу), килешү буенча эшләр өчен түләү

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Җыенны оештыручы итеп Чистай муниципаль районының Кубас авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чистай муниципаль районының
Кубас
авыл җирлеге башлыгы                                                  Логинова Н.С.